6+

РИНАТ
НУРУЛЛИН





# УКЫМЫШЛЫ ЧЫПЧЫКЛАР



ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Н80

Рәссамы *Марат Рәхимов*

**Нуруллин, Р. Г.**
Н80 Укымышлы чыпчыклар : балалар өчен шигырьләр һәм әкият / Ринат Нуруллин ; [рәссамы Марат Рәхимов]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. — 127 б.
ISBN 978-5-298-03347-3

Ринат Нуруллин үз шигырьләрен мавыктыргыч башваткычлар, табышмаклар һәм тапкырлык таләп иткән шарадалар рәвешендә бирә. Алар зирәклекне арттыра һәм эзлекле фикер йөртергә, чынбарлыкны дөрес аңларга өйрәтә.

Әлеге китап — математиканы тирәнрәк үзләштерер өчен менә дигән ярдәмлек.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03347-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2017
© Нуруллин Р. Г., 2017

# Эчтәлек


Якты сүз . . . 3
Төсләр . . . 3
Артык сүз . . . 3
Өчтән — бер . . . 4
Кем икәнен танырсызмы? . . . 4
Шомырттагы кошлар . . . 5
Балыкчылар . . . 5
Ач сан . . . 5
Сана банан! . . . 6
Кавын тавы . . . 6
Бармак барлау . . . 7
Автоматематика . . . 7
Тәпиләр . . . 8
Әкәм-төкәм . . . 8
Торналар . . . 9
Укымышлы чыпчыклар . . . 10
Хыялый балыкчы . . . 11
Бураннан соң . . . 12
Дүртенче вагонга керсәң... . . . 13
Муса һәм сумса . . . 14
Җир шары һәм алма . . . 15
Саннар бии . . . 16
Кич ич! . . . 17
Коңгыж-ж-ж . . . 18
Композитор камка . . . 19
Сак-сак тотсак! . . . 20
Кушсаң, бүлсәң, тапкырласаң... . . . 21
Карга карга баткан . . . 22
Әгәр-мәгәр . . . 23
Тутый бутый . . . 24
Суыткыч иясе . . . 26
Сабактуй . . . 27
Баобабай . . . 28
Баобабай-2 . . . 29
Алга!!! . . . 30
Канатлы песи . . . 32
Затлы чылбыр . . . 33
Канатлы такмаклар . . . 34
Мыеклы ребус . . . 37
Хисмәтнең хикмәтләре . . . 38
    Чаңгычылар ярышында . . . 38
    Биюче тукмак . . . 38
    Тимер кошлар . . . 39
    Эшләпәле бабай . . . 39
Камыр батыр . . . 40

Татарлар борынгы чорда файдаланган кайбер үлчәү берәмлекләре . . . 86
Чишү ысуллары һәм җаваплар . . . 88

## ЯКТЫ СҮЗ



Ике иҗектән торган сүз —
Якты, гүя аҗаган.
Беренчесен умарталар
Җыя чәчәк таҗыннан.

Икенчесе килеп җитсә,
Карлы бураннар исә.
Бик матур сүзне табарсың,
Эзләргә тотсаң исәп.

## ТӨСЛӘР

«Сарык»та сары төс булса,
Ак төс булса «бака»да,
«Күке»дән күк төсне тапсаң,
Нинди төс бар «шалкан»да?

## АРТЫК СҮЗ

Хайван исемнәрен җыеп,
Сүзләр тездем бер рәткә:
Бүре, тиен, куян, сыер,
Поши, ишәк, эт, тәкә.

Сүзләр чылбырында берсе
Артык булып тоела.
Чагыштырып, әйтеп бирче,
Нигә ул аерыла?



## ӨЧТӘН — БЕР

Өч сүз бергә кушылса,
Җир астыннан шуыша.

Беренче сүз — сыекча,
Кышын кар булып оча.

Сүзләрнең икенчесе —
Таң атканда, күк төсе.

Килеп тә җиттек өчкә:
Өченче сүз — дәү мичкә.

Нәрсә шуышканын без
Икәү генә белербез.



## КЕМ ИКӘНЕН ТАНЫРСЫЗМЫ?



Лачындай батыр йөрәкле
Егете ул татарның!
Роман-мазар булмаса да,
Оста язган шигырьләре
Нәниләргә күп аның.

Лаек мактау-хөрмәткә ул:
Әсәрләрен балалар
Бик яратып укыйлар.
Исемен беләсең килсә —
Баш хәрефләрдә ул бар!



## ШОМЫРТТАГЫ КОШЛАР

Шомырт ботагына кунды
Ике песнәк, биш чыпчык.
Барлыгы ничә кош булды
Шул ботакта, санап чык!



## БАЛЫКЧЫЛАР

Биш ташбаш тоткан Җәмил,
Өч ташбаш тоткан Хәбир.
Ничә балык тоткан бергә
Бу малайлар, әйтеп бир!



## АЧ САН

Кешеләр төрле булганча,
Саннарның төрлесе бар:
Берсе юан, берсе ябык,
Берсе җөп, берсе сыңар.

Ашамыйча йөргәнгәдер,
Эче буш «ноль» санының.
Нинди сан барлыкка килә,
Тамагы туйса аның?





## САНА БАНАН!

Әни маймыл сатып алган
Базардан унбиш банан.
Шулкадәр күп алмас иде —
Үстерә ич биш бала.

Маймыл балалары тәмләп
Өчәр банан ашаган.
Әни маймылның үзенә
Никадәр банан калган?

## КАВЫН ТАВЫ

Сатып алдык ун кавын,
Өеп куйдык дәү тавын.
Ләкин шул тау озак итеп
Биләмәде күз явын.

Берсен бирдек әбигә,
Апам алды алтысын.
Әйтеп бир, үзебезгә
Ничә кавын калды соң?



## БАРМАК БАРЛАУ

Беренче кулда
Беренче бармак
Беренче була —
Йөрмә дә барлап.

Икенче кулда
Икенче бармак
Ничәнче була? —
Бир әле санап!



## АВТОМАТЕМАТИКА

Машиналар ашыгалар,
Төрле йөкләр ташыйлар.
Солы, арпа, печән түгел,
Алар бензин ашыйлар.

Карбюратор аша бактан
Бензинны чөмерәләр,
Мотор эчендә яндырып,
Юллардан йөгерәләр.

Билгеле ки: йөз чакрымга
Бер чиләк бензин җитә.
Казаннан Мәскәүгә барсаң,
Нихәтле бензин китә?



## ТӘПИЛӘР



Казның ике тәпие бар,
Ә куянныкы — дүртәү.
Алты казның, бер куянның
Тәпиләр саны ничәү?

## ӘКӘМ-ТӨКӘМ

Бер минутта әкәм-төкәм
Дүрт сантиметр үтә.
Бер сәгатьтә күпме ара
Ул узачак, кем әйтә?



## ТОРНАЛАР



Сазда йөри торналар:
Тәпиләре — тырмалар,
Борыннары — бүрәнкә,
Гәүдәләре — гәрәнкә,
Ә канатларын җәйсәләр,
Ике метрга җитә.



Түмгәкләрдә торналар
Ояларын коралар.
Тик тормаса да, алар:
«Торыйк!» — дип кычкыралар.
Ризык-тәгам торна өчен —
Бөҗәкләр һәм бакалар.

Озакламый көз җитәр,
Очар ике кисемтә
Торналар чылбырыннан,
Ярып күкне чөй сыман.
Бары тик хисләр, сораулар
Калыр алар артыннан.

Мондый сорауга җавап
Белем сазлыгын урап
Эзләнгән кеше табар,
Беренчелекне яулар:
Торна исемендә нинди
Геометрик җисем бар?



## УКЫМЫШЛЫ ЧЫПЧЫКЛАР

Китапханә түбәсенә
Җиде чыпчык утырган.
Һәрбер чыпчык, күзлек киеп,
Җиде китап укыган.

Белем җимен чүпләп, кошлар
Очкан хыял иленә.
Артларыннан исеп калган
Сораулар җиле генә.

Шул сорауларның берсенә
Җавап тапмадым мин дә:
Ничә китап кирәк булган
Чыпчыкларга кимендә?



## ХЫЯЛЫЙ БАЛЫКЧЫ

Кармак сабы, шырпы кабы —
Суалчаннар ятагы...
Шулардан тыш балыкчыга
Ни кирәк булсын тагын?

Аласың да суалчанны,
Киертәсең инәгә.
Шул суалчанга төкерсәң,
Иң зур балык эләгә!

Егерме дүрт сантиметр
Булса балыкның буе,
Күрсәтер идем дусларга,
Биш тапкыр зуррак куеп.

Ышанмасалар бу хәлгә,
Өч мәртәбә киметәм...
Шулай иткәч, балык буе
Күпме зурлыкка җитә?





## БУРАННАН СОҢ

Хәниф белән Мөниф иртән
Кар көрәргә чыкканнар,
Икесе дә кулларына
Кар көрәге тотканнар.

Бергәләп эш эшләгәндә,
Нәтиҗә була ишле:
Хәниф өч көрәк атканда,
Мөниф томыра бишне.

«Йөз көрәк кар ыргыттым!» — дип
Мактанып куйды Мөниф.
«Ә мин санап тормадым», — дип
Җавап кайтарды Хәниф...

Әгәр башваткыч яратсаң,
Санап бир әле яттан:
Хәниф белән Мөниф бергә
Ничә көрәк кар аткан?

